**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авыл торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019 елның 1 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче торак пунктлары чикләрендә юлларны карап торуга һәм ремонтлауга;
- Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктларындагы православие зиратын төзекләндерүгә;
- 4 данә евроконтейнер сатып алуга һәм Гремячка авылында контейнер мәйданчыгына козырек урнаштыруга;
- энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм авыл җирлеге торак пунктында урнаштыруга.

ӘЙЕ ЮК”

соравы (мәсьәләсе) буенча 2019 елның 30 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 207 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенда катнашучыларның 120 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 120 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авыл торак пунктында гражданнар җыенын **булды** дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тору һәм ремонтлауга;

- Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктларындагы православие зиратын төзекләндерүгә;

- 4 данә евроконтейнер сатып алуга һәм Гремячка авылында контейнер мәйданчыгына козырек урнаштыруга;

- энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм авыл җирлеге торак пунктында урнаштыруга?”

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Троицкий Урай авылы Прикамская урамы, 9 йорт; Гремячка авылы Александров урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Троицкий Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин